| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**11.04.2019** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 861** |

Зеленодольск шәһәренең Энгельс урамындагы 10 нчы, 12 нче күпфатирлы йортларга капиталь ремонтлау эшләрен башлау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 мартындагы 550-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольскгаз» эксплуатация – җитештерү берләшмәсенә, «ЗВКС» АҖ, Идел буе бүлекчәсе Зеленодольск ОКО -«Татэнергосбыт» ААҖ түбәндәге адреслар буенча торак йортларны коммуникацияләрдән өзәргә тәкъдим итәргә:
- Зеленодольск шәһәре, Энгельс ур, 10 нчы йорт;
- Зеленодольск шәһәре, Энгельс ур., 12 нче йорт.
2. 2019 елның 12 апреленнән «Жилкомплекс» ҖЧҖ идарәче компаниясенә күпфатирлы йортлар белән идарә итүне һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүләрне исәпләүне туктатып торуны гамәлгә ашырырга.
3. 2019 елның 12 апреленнән «Татинвестстрой» ҖЧҖ подрядчыларына күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләренә керешергә. Дәүләт контракты шартлары нигезендә күпфатирлы йортларга капиталь ремонтлау эшләрен төгәлләү срогын 2019 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә .
4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче Д.А. Сапожников